СОВЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

16.12.2019 г.Зеленодольск № 456

2020 елга Зеленодольск муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның фараз планы (программасы) турында

2020 елга Зеленодольск муниципаль районының Башкарма комитеты тарафыннан тәкъдим ителгән Зеленодольск муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның Фараз планын (программасын) карап, 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы «Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында»гы Федераль закон нигезендә эшләнгән, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы Федераль законга, Зеленодольск муниципаль районы Советының 2006 елның 29 ноябрендәге 111 номерлы карары белән расланган Зеленодольск муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру тәртибе турында нигезләмәгә, Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Зеленодольск муниципаль районы Советының карар **кабул итте:**

1. Зеленодольск муниципаль районының 2020 елга муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның фараз планын кушымта нигезендә расларга.
2. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетына «Интернет» челтәрендә 2020 елга Зеленодольск муниципаль районының муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның фаразлау планын (программаларын) Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районы мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru), торглар үткәрү турында мәгълүмат урнаштыру өчен Россия Федерациясенең рәсми сайтында (http://www.torgi.gov.ru) урнаштыруны тәэмин итәргә.

**Зеленодольск муниципаль районы**
**Башлыгы урынбасары** **Э.Р. Кадникова**

- Зеленодольск муниципаль районы Советының
2019 елның 16 декабрендәге
456 номерлы карарына
кушымта

**2020 елга Зеленодольск муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның фараз планы (программасы)**

I. Гомуми нигезләмә

1. 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы «Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» Федераль закон, 2006 елның 29 ноябрендәге 111 номерлы Зеленодольск муниципаль районы Советы карары белән расланган Зеленодольск муниципаль районының муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру тәртибе турында нигезләмә нигезендә, 2020 елга Зеленодольск муниципаль районының муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның фаразлау планы (программасы) эшләнде.

2. 2020 елда Зеленодольск муниципаль районының муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру район милкенең структурасын оптимальләштерүгә, хосусыйлаштыру объектларына инвестицияләр җәлеп итүгә, район бюджеты керемнәрен арттыруга юнәлдерелгән.

3. Муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы «Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында»гы Федераль законда каралган ысуллар белән гамәлгә ашырыла.

4. Зеленодольск муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның фараз планы (программасы) гамәлдә булганда, хосусыйлаштырыла торган мөлкәт исемлегенә Зеленодольск муниципаль районы Советы карарлары нигезендә үзгәрешләр кертелергә мөмкин.

II. 2020 елда хосусыйлаштырылырга тиешле муниципаль мөлкәт

Хосусыйлаштыруга планлаштырыла торган башка мөлкәт исемлеге

| № т/б | Исеме | **Мөлкәтнең урнашу урыны** | **Хосусыйлаштыруның фараз ителгән срогы** |
|---|---|---|---|
| 1 | 1 катлы, мәйданы 346,5 кв.м., 1973 елгы торак булмаган бина янкормасы (А литеры) | **Татарстан Республикасы, Зеленодольск шәһ., Тургенев ур., 4** | 2020 елның I-III кварталы |